Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы карары

2024 елның 10 июне №100

Җирле салымнар суммалары өлешендә
бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына ярашлы рәвештә, җирле салымнар суммалары өлешендә өметсез бурычны түләтүне җайга салу максатыннан, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә.

2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә исәпләнелә торган, түләү һәм (яисә) түләттерү мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендәге бурыч түбәндәге нигезләр буенча түләтүгә ышанычсыз дип таныла:

1)варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яисә индивидуаль эшкуарларга исәпләнелә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр булуны раслый торган документлар (белешмәләр) булып түбәндәгеләр тора:

1) әлеге карарның 2 статьясының 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) вафат булуга бәйле рәвештә, физик затны салым исәбеннән алу хакындагы белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммалары хакында оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, датасы, номеры);

3) әлеге Законның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда –500 сумнан артмаган суммада бурыч булу хакында салым органы белешмәсе.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының «җирле салымнар өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 15 маендагы 72 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Балтач авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга:

-ТР,Кама Тамагы районы,Балтач ав.,Мэктэп ур.,1 йорт;

-ТР,Кама Тамагы районы, Балтач ав.,Мәктәп ур.,2 йорт.

Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балтач авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Балтач
авыл җирлеге башлыгы ,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Балтач
авыл җирлеге Совет рәисе Д.И.Мөхәммәдуллин